КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 9 август г.Казань № 960

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Югары һөнәр белеме бирүче «Н.Г.Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе» федераль дәүләт белем учреждениесе фәнни-белем бирү кластерын оештыру турында» 2011 ел, 12 апрель, 286 нчы карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Югары һөнәр белеме бирүче «Н.Г.Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе» федераль дәүләт белем учреждениесе фәнни-белем бирү кластерын оештыру турында» 2011 ел, 12 апрель, 286 нчы карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 21 май, 334 нче; 2015 ел, 25 декабрь, 983 нче, 2016 ел, 27 длекабрь, 1002 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

исемендә «Н.Г.Җиһанов ис.» сүзләрен «Н.Г.Җиһанов исемендәге» сүзләренә алмаштырырга;

1 пунктта «Н.Г.Җиһанов ис.» сүзләрен «Н.Г.Җиһанов исемендәге» сүзләренә алмаштырырга;

2 пунктта:

икенче абзацта «Н.Г.Җиһанов ис.» сүзләрен «Н.Г.Җиһанов исемендәге» сүзләренә алмаштырырга;

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Н.Г.Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе» федераль дәүләт югары белем бирү мәгариф учреждениесенең фәнни-мәгариф кластеры турында нигезләмә»;

3 пункт үз көчен югалткан дип танырга;

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгына «Н.Г.Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе» федераль дәүләт югары белем бирү мәгариф учреждениесенең фәнни-мәгариф кластерында катнашучылар арасында үзара хезмәттәшлек турында килешү формасын эшләргә һәм Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы боерыгы белән расларга.»;

5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләренең башкарма комитетларына алар, мәдәният өлкәсендә алар буйсынуындагы өстәмә белем бирү мәгариф оешмалары һәм Татарстан Республикасы Мәдәният министрлыгы буйсынуындагы, «Н.Г.Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе» федераль дәүләт югары белем бирү мәгариф учреждениесенең фәнни-мәгариф кластеры составына керүче театр-тамаша оешмалары арасында төзелә торган килешү формасын эшләргә һәм расларга тәкъдим итәргә.»;

әлеге карар белән расланган «Н.Г.Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе» федераль дәүләт югары белем бирү мәгариф учреждениесенең фәнни-мәгариф кластеры составын яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә);

Әлеге карар белән расланган «Н.Г.Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе» федераль дәүләт югары белем бирү мәгариф учреждениесенең фәнни-мәгариф кластеры турында нигезләмәне яңа редакциядә бәян итәргә (кушымта итеп бирелә).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2011 ел, 12 апрель, 286 нчы
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 9 август, 960 нчы
карары редакциясендә)

## Н.Г.Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе» федераль дәүләт югары белем бирү мәгариф учреждениесенең фәнни-мәгариф кластеры турында нигезләмә

### I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Мәдәниятне үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында» 2014 елның 15 апрелендәге 317 номерлы карары белән расланган «Мәдәниятне үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Мәгарифне үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасын раслау турында» 2017 елның 26 декабрендәге 1642 номерлы карары белән расланган «Мәгарифне үстерү» Россия Федерациясе дәүләт программасы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2015 елның 24 ноябрендәге 2395-б номерлы боерыгы белән расланган 2025 елга кадәр Россия Федерациясендә академик музыка өлкәсендә концерт эшчәнлеген үстерү концепциясе, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 29 февралендәге 326-б номерлы боерыгы белән расланган 2030 елга кадәр чорга дәүләт мәдәни сәясәте стратегиясе, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы мәдәниятен үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 16 декабрь, 997 нче карары белән расланган «Татарстан Республикасы мәдәниятен үстерү» дәүләт программасы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2030 елга кадәр чорга Татарстан Республикасы мәдәниятен үстерү стратегиясен раслау турында» 2021 ел, 17 май, 344 нче карары белән расланган 2030 елга кадәр чорга Татарстан Республикасы мәдәниятен үстерү стратегиясе нигезендә эшләнде.

1.2. Әлеге Нигезләмә Н.Г.Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе» федераль дәүләт югары белем бирү мәгариф учреждениесенең фәнни-мәгариф кластеры (алга таба - Кластер) максатларын һәм бурычларын, составын һәм структурасын, Кластерны гамәлгә ашыру механизмнарын һәм үстерүнең өстенлекле юнәлешләрен билгели.

1.3. Әлеге Нигезләмәдә аннан файдалану максатлары өчен түбәндәге терминнар кулланыла:

Казан консерваториясе– югары белем бирүче «Н.Г.Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе» федераль дәүләт бюджет мәгариф учреждениесе;

Кластер - сәнгать өлкәсендә югары һәм урта һөнәри белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы һөнәри белем бирү оешмалары, музыкаь сәнгате өлкәсендә өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы Татарстан

Республикасы дәүләт һәм муниципаль мәгариф оешмалары, Татарстан Республикасының театр-тамаша оешмалары - музыка сәнгате өлкәсендә төп эш бирүчеләр җыелмасы;

Кластер советы - югары һәм урта һөнәри белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы һөнәри уку йортлары вәкилләре, Кластер составына керүче, эшчәнлекнең штаблары һәм координаторлары функцияләрен гамәлгә ашыручы оешмалар вәкилләре, музыка сәнгате өлкәсендә эш бирүче оешмалар вәкилләре.

## II. Кластерның максатлары һәм бурычлары

2.1. Кластерның максатлары:

музыка сәнгате өлкәсендә илебезнең өч баскычлы уникаль мәгариф системасын саклап калу һәм үстерү;

музыка сәнгате өлкәсендә квалификацияле хезмәткәрләр әзерләү;

Татарстан Республикасы театр-тамаша һәм музыка-белем бирү учреждениеләрен югары профессионал кадрлар белән тәэмин итү;

музыка сәнгате өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт оешмалары һәм муниципаль оешмалар хезмәткәрләренең һөнәри дәрәҗәсен күтәрү.

2.2. Кластерның бурычлары:

Кластерның музыка сәнгате өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт оешмаларының һәм муниципаль оешмаларның бердәм челтәрен булдыру һәм аның дәрәҗәләренең системалы эшен оештыру;

мәгариф оешмаларының потенциаль эш бирүчеләр белән үзара хезмәттәшлеген булдыру, остазлык һәм җитештерү практикасы системасын үстерү;

балалар сәнгать мәктәпләрендә һәм балалар музыка мәктәпләрендә сәнгать өлкәсендә гамәлгә ашырыла торган өстәмә һөнәри программаларның саны һәм сыйфаты үсешен тәэмин итү;

«Татар музыкасы гасыры - Татарстан аһәңнәре» интернет-порталында Кластер эше турында мәгълүмат бастырып чыгару, ул идарә системасының заманча цифрлы инструменты буларак ачык мәгълүматлар сәясәтен кертүгә ярдәм итә;

музыкаль сәнгать өлкәсендә хезмәткәрләрне методик, иҗади, һөнәри осталыкның өзлексез үсешен тәэмин итә торган музыкаль сәнгать өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт оешмалары һәм муниципаль оешмалар хезмәткәрләрен укытуның һәм аларның квалификациясен күтәрүнең югары нәтиҗәле системасын оештыру;

музыка сәнгате өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт оешмалары һәм муниципаль оешмалар хезмәткәрләренең цифрлы һәм мәгълүмати-коммуникатив компетенциясе дәрәҗәсен күтәрүгә, шул исәптән цифрлы инструментларны кулланып, укытуның яңа технологияләрен гамәлгә кертүгә ярдәм итү;

музыкаль-белем бирү һәм мәдәни-агарту проектларын оештыру һәм уздыру системасын төзү;

Татарстан Республикасы яшьләре арасында музыкант һөнәренең имиджын арттыруга юнәлдерелгән мәдәни акцияләрне һәм агарту проектларын гамәлгә ашыру.

## III. Кластерны үстерүнең өстенлекле юнәлешләре

Кластер эшчәнлеге түбәндәге төп үсеш юнәлешләре тирәсендә туплана:

системалы-оештыру юнәлеше (Кластер белән идарә итү системасы эшчәнлеге);

мәгариф юнәлеше (музыка сәнгате өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт оешмалары һәм муниципаль оешмалар хезмәткәрләренең квалификациясен күтәрү, укыту системасын модернизацияләү һәм алдынгы технологияләрне гамәлгә кертү);

тәрбияви юнәлеш (шәхесне үстерү, белем алучыларны социомәдәни, рухи-әхлакый кыйммәтләр, үзара хөрмәт, мәдәни мираска һәм Россия Федерациясенең күпмилләтле халкы традицияләренә нигезләнеп үз-үзен тормышка ашыру һәм социальләштерү өчен шартлар тудыру);

иҗади юнәлеш (музыка сәнгате өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль оешмаларында укучыларның һәм хезмәткәрләрнең иҗади потенциалын үстерү, иҗади хезмәттәшлекнең яңа рәвешләрен формалаштыру);

музыкаль-агарту юнәлеше (Татарстан Республикасы территориясендә һәм аннан читтә музыка сәнгате һәм иҗат казанышларын популярлаштыру);

мәгълүмати-аналитик юнәлеш һәм ачык мәгълүматлар өлкәсе (Кластер эшчәнлеге турында мәгълүматлар базасын булдыру, аның өстенлекле юнәлешләре буенча даими рәвештә нәтиҗәләрне мониторинглау, шулай ук киң мәгълүмат киңлегендә, шул исәптән «Татар музыкасы гасыры - Татарстан аһәңнәре» интернет-порталында һәм массакүләм мәгълүмат чараларында Кластер нәтиҗәләрен һәм казанышларын трансляцияләү);

һөнәри ориентация юнәлеше (музыка сәнгате өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль оешмаларында укучыларга киләчәктә укыту, эшкә урнашу, һөнәри үсеш мөмкинлекләре турында мәгълүмат бирүне тәэмин итү).

## IV. Кластерның составы һәм Кластерны гамәлгә ашыру механизмнары

4.1. Кластерның составы:

әлеге Нигезләмәгә кушымтага ярашлы рәвештә сәнгать өлкәсендә югары һәм урта һөнәри белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы һөнәри белем бирү оешмалары, музыкаь сәнгате өлкәсендә өстәмә белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль мәгариф оешмалары, Татарстан Республикасының театр-тамаша оешмалары - музыка сәнгате өлкәсендә төп эш бирүчеләр җыелмасы;

Кластерның баш оешмасы - Казан консерваториясе.

4.2. Кластер составы төгәл түгел һәм Татарстан Республикасының мәдәният өлкәсендәге челтәр һәм инфраструктура үзгәрешләре нигезендә тулыланырга мөмкин.

4.3. Казан консерваториясе стратегияне билгели, чаралар планын һәм аларның нәтиҗәлелеге күрсәткечләрен формалаштыра.

4.4. Казан консерваториясе онлайн- һәм офлайн-режимнарда, методик, консультация, иҗади ярдәм күрсәтүдә, Кластерның белем бирү программаларын оештыруда, Казан консерваториясенең стратегик проектларын гамәлгә ашыруга җәлеп итүдә, Кластер эшчәнлеген мониторинглауны һәм анализлауда, эш бирүче

оешмалар белән музыкаль сәнгать өлкәсендә үзара хезмәттәшлекне координа-цияләүдә Кластерның эшчәнлеген тәэмин итә.

4.5. Кластерның челтәр мәйданчыгы - «Татар музыкасы гасыры - Татарстан аһәңнәре» интернет-порталы, анда концерт һәм белем бирү чаралары турында мәгълүмат бастырыла, вебинарлар үткәрелә һәм концертлар трансляцияләнә. Челтәр мәйданчыгы эшен тәэмин итү Кластерның баш оешмасына йөкләнә.

## V. Кластер советы

5.1. Кластер советы Кластерның үсешенең төп юнәлешләрен билгеләүдә катнашучы иҗтимагый идарә органы булып тора.

5.2. Кластер Советы рәисе - Казан консерваториясе ректоры.

5.3. Кластер советына югары һәм урта һөнәри белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы һөнәри уку йортлары вәкилләре, Кластер составына керүче, эшчәнлекнең штаблары һәм координаторлары функцияләрен гамәлгә ашыручы оешмалар вәкилләре, музыка сәнгате өлкәсендә эш бирүче оешмалар вәкилләре керә.

5.4. Кластер Советы вәкаләтләре:

Кластер составын үзгәртү турында тәкъдимнәр кертергә;

Кластерны үстерүнең оештыру структурасы һәм стратегиясе буенча тәкъдимнәр кертергә;

Татарстан Республикасы музыка сәнгате өлкәсендә кадрлар ихтыяҗларын фаразлауда катнашырга;

әлеге Нигезләмәнең III бүлегендә билгеләнгән өстенлекле үсеш юнәлешләре буенча Кластерның чаралар планын формалаштыруда һәм гамәлгә ашыруда катнашырга;

музыка сәнгате өлкәсендә Татарстан Республикасы дәүләт оешмаларын һәм муниципаль оешмаларны тәмамлаучыларны эшкә урнаштыруга ярдәм итәргә;

Кластер эшчәнлегенә мәгълүмати ярдәм күрсәтергә, аның нәтиҗәләрен һәм чараларын пропагандаларга.

5 .5. Кластер Советының эшчәнлек формасы булып Кластер Советы утырышлары тора.

5.6. Кластер Советы утырышлары көндезге, көндезге-читтән торып, читтән торып үткәрелергә мөмкин.

5.7. Кластер Советы утырышлары елына кимендә ике тапкыр уздырыла. Кластер Советының чираттан тыш утырышлары кирәк саен үткәрелергә мөмкин.

Кластер Советы утырышларын онлайн режимында уздыру рөхсәт ителә.

5.8. Кластер Советы утырышлары, әгәр аларда Кластер Советы әгъзаларының яртысыннан да ким булмаган өлеше катнашса, хокуклы булып тора. Кластер Советы әгъзалары вәкаләтләрен башка затларга бирү рөхсәт ителми.

5.9. Кластер Советы утырышларына дәүләт һәм муниципаль мәдәният учреждениеләрен гамәлгә куючылар вәкилләре, музыка сәнгате һәм мәгариф өлкәсендәге экспертлар чакырыла ала.

5.10. Кластер Советы карарлары Кластер Советы утырышында катнашучы Кластер Советы әгъзаларының ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда, хәлиткеч тавыш хокукына Кластер Советы рәисе ия.

## VI. Кластерның пространство структурасы

6.1. Кластерда кулланыла торган идарә структурасына оператив хезмәттәшлек һәм тәэсир итү функцияләре, шулай ук Татарстан Республикасының икътисадый зоналары чикләрендә гамәлдә булган Кластерда катнашучыларның эшчәнлеген стратегик планлаштыру һәм анализлау функцияләре бирелә торган махсуслаштырылган бүлекчәләр кирә.

6.2. Кластер Советы составы оешмаларыннан Татарстан Республикасының алты икътисадый зонасы билгеләнде :

| Т/с | Татарстан Республикасының икътисадый зоналары | Татарстан Республикасының муниципаль берәмлекләре | Кластер Советы исәбеннән Кластер вәкилләре |
|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 |
| 1. | Казан агломерациясе һәм Башкала икътисадый төбәге | Әтнә, Арча, Югары Ослан, Биектау, Зеленодольск, Лаеш, Питрәч муниципаль районнары, Казан шәһәре | «И.В.Әүхәдиев исемендәге Казан музыка көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе;<br>Казан шәһәренең «П.И.Чайковский исемендәге 1 нче балалар музыка мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе;<br>«Муса Җәлил исемендәге Татар академия дәүләт опера һәм балет театры» дәүләт бюджет учреждениесе;<br>«Салих Сәйдәшев исемендәге Зур концерт залы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе;<br>«Татарстан Республикасының Дәүләт академия симфоник оркестры» Татарстан Республикасы дәүләт автоном мәдәният учреждениесе;<br>«София Гобәйдуллинаның заманча музыка үзәге» Казан шәһәре муниципаль бюджет мәдәният учреждениесе |
| 2. | Чаллы агломерациясе һәм икътисадый зонасы | 1 нче ярдәмче зона:<br>Әгерҗе, Актаныш, Минзәлә, Мөслим, Менделеевск муни- | «Чаллы сәнгать көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе; |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | | ципаль районнары, Чаллы шәһәре | Чаллы шәһәренең «1 нче балалар музыка мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль автоном учреждениесе; |
| | | 2 нче ярдәмче зона: Алабуга, Зәй, Түбән Кама, Тукай муниципаль районнары | «Салих Сәйдәшев исемендәге Түбән Кама музыка көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе; Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «1 нче балалар музыка мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе |
| 3. | Көньяк-Көнчыгыш икътисадый зонасы | Азнакай, Әлмәт, Баулы, Бөгелмә, Лениногорск, Сарман, Чирмешән, Ютазы муниципаль районнары | «Ф.З.Яруллин исемендәге Әлмәт музыка көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе; Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «Р.Н.Нәгыйимов исемендәге 1 нче балалар музыка мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе |
| 4. | Кама арты икътисадый зонасы | Аксубай, Алексеевск, Әлки, Яңа Чишмә, Нурлат, Спас, Чистай муниципаль районнары | «Н.Г.Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесе; Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «С.Гобәйдуллин исемендәге балалар сәнгать мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет оешмасы |
| 5. | Кама алды икътисадый зонасы | Балтач, Кукмара, Мамадыш, Балык Бистәсе, Саба, Теләче муниципаль районнары | «Н.Г.Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесе; Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль рай- |

| 1 | 2 | 3 | 4 |
|---|---|---|---|
| | | | онының «Композиторлар Яруллиннар исемендәге Мамадыш шәһәре балалар сәнгать мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе |
| 6. | Идел алды икътисадый зонасы | Апас, Буа, Чүпрәле, Кайбыч, Кама Тамагы, Тәтеш муниципаль районнары | «Н.Г.Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесе;<br>«1 нче Буа балалар сәнгать мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет оешмасы |

Н.Г. Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе» федераль дәүләт югары белем бирү мәгариф учреждениесенең фәнни-мәгариф кластеры турында нигезләмәгә кушымта

Н.Г.Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе» федераль дәүләт югары белем бирү мәгариф учреждениесенең фәнни-мәгариф кластеры Советы составы

«Н.Г.Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесе;

«И.В.Әүхәдиев исемендәге Казан музыка көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе - академик музыка сәнгате штабы;

«Ф.З.Яруллин исемендәге Әлмәт музыка көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе - музыкаль инструментарийны һәм традицион инструменталь башкаручыны өйрәнү штабы;

«Чаллы сәнгать көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе - музыка сәнгате өлкәсендә дисциплинара хезмәттәшлек штабы;

«Салих Сәйдәшев исемендәге Түбән Кама музыка көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе;

«Муса Җәлил исемендәге Татар академия дәүләт опера һәм балет театры» дәүләт бюджет учреждениесе;

«Салих Сәйдәшев исемендәге Зур концерт залы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе;

«Татарстан Республикасының Дәүләт академия симфоник оркестры» Татарстан Республикасы дәүләт автоном мәдәният учреждениесе;

«София Гобәйдуллинаның заманча музыка үзәге» Казан шәһәре муниципаль бюджет мәдәният учреждениесе;

Казан шәһәренең «П.И.Чайковский исемендәге 1 нче балалар музыка мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе;

Чаллы шәһәренең «1 нче балалар музыка мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль автоном учреждениесе;

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «1 нче балалар музыка мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе;

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «Р.Н.Нәгыймов исемендәге 1 нче балалар музыка мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе;

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «С.Гобәйдуллин исемендәге балалар сәнгать мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет оешмасы;

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының «Композиторлар Яруллиннар исемендәге Мамадыш шәһәре балалар сәнгать мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе;

«1 нче Буа балалар сәнгать мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет оешмасы.

---

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2011 ел, 12 апрель, 286 нчы
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2023 ел, 9 август, 960 нчы
карары редакциясендә)

Н.Г.Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе» федераль дәүләт югары белем бирү мәгариф учреждениесенең фәнни-мәгариф кластеры составы

«Н.Г.Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясе» федераль дәүләт бюджет югары белем бирү мәгариф учреждениесе;

«И.В.Әүхәдиев исемендәге Казан музыка көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе;

«Ф.З.Яруллин исемендәге Әлмәт музыка көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе;

«Чаллы сәнгать көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе;

«Салих Сәйдәшев исемендәге Түбән Кама музыка көллияте» дәүләт автоном һөнәри белем бирү учреждениесе;

Казан шәһәренең «П.И.Чайковский исемендәге 1 нче балалар музыка мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе;

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «Р.Н.Нәгыйимов исемендәге 1 нче балалар музыка мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе;

«1 нче Буа балалар сәнгать мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет оешмасы;

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының «Композиторлар Яруллиннар исемендәге Мамадыш шәһәре балалар сәнгать мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе;

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «1 нче балалар музыка мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе;

Чаллы шәһәренең «1 нче балалар музыка мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль автоном учреждениесе;

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «С.Гобәйдуллин исемендәге балалар сәнгать мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет оешмасы;

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Азнакай балалар сәнгать мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет мәгариф учреждениесе;

Татарстан Республикасы «Актаныш муниципаль районы балалар сәнгать мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет мәгариф учреждениесе;

Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының «Алексеевск балалар сәнгать мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет оешмасы;

Татарстан Республикасы Әлки муниципаль районының «Әлки балалар музыка мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет оешмасы;

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «2 нче балалар музыка мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль автоном мәгариф учреждениесе;

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «3 нче балалар музыка мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе;

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «1 нче балалар сәнгать мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет мәгариф учреждениесе;

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «2 нче балалар сәнгать мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе;

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районының «Арча балалар сәнгать мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет оешмасы;

Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районының «Балалар сәнгать мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль автоном учреждениесе;

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының «Балалар сәнгать мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе;

Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының «Бөгелмә балалар сәнгать мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет мәгариф учреждениесе;

Татарстан Республикасы Бөгелмә муниципаль районының «2 нче Бөгелмә балалар сәнгать мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет мәгариф учреждениесе;

Татарстан Республикасы «Югары Ослан муниципаль районы балалар сәнгать мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет мәгариф учреждениесе;

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының «С.Сәйдәшев исемендәге сәнгать мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе;

Татарстан Республикасы Чүпрәле муниципаль районының «Балалар сәнгать мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе;

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының «Ә.Бакиров исемендәге 1 нче балалар музыка мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе;

Татарстан Республикасы Алабуга муниципаль районының «А.Т.Гәрәев исемендәге 2 нче балалар музыка мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе;

Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының «Зәй балалар музыка мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе;

Зеленодольск шәһәренең «Балалар музыка мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе;

Зеленодольск шәһәренең «Балалар сәнгать мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе;

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының «Кайбыч балалар сәнгать мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе;

Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районының «Кукмара балалар музыка мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе;

Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Лаеш шәһәренең «Балалар сәнгать мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе;

Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районының «Н.М.Кудашев исемендәге Лениногорск балалар музыка мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе;

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының «Балалар сәнгать мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе;

Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының «Мөслим балалар сәнгать мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе;

Чаллы шәһәренең «2 нче балалар музыка мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль автоном учреждениесе;

Чаллы шәһәренең «3 нче балалар музыка мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе;

Чаллы шәһәренең «4 нче балалар музыка мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль автоном учреждениесе;

Чаллы шәһәренең «5 нче балалар музыка мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль автоном учреждениесе;

Чаллы шәһәренең «С.Сәйдәшев исемендәге 6 нчы балалар музыка мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль автоном учреждениесе;

Чаллы шәһәренең «Балалар сәнгать мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль автоном учреждениесе;

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «2 нче балалар музыка мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе;

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «Йолдызлык» балалар сәнгать мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе;

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «4 нче балалар музыка мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе;

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «5 нче балалар музыка мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе;

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «6 нчы балалар музыка мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе;

Татарстан Республикасы Түбән Кама муниципаль районының «Кама Аланы балалар музыка мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе;

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының «Яңа Чишмә балалар сәнгать мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе;

Татарстан Республикасы Нурлат муниципаль районының «Нурлат балалар сәнгать мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе;

Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районының «Балалар сәнгать мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе;

«Хөснулла һәм Аллаһияр Вәлиуллиннар исемендәге Саба балалар сәнгать мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет мәгариф учреждениесе;

Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «М.Г.Юзлибаев исемендәге Җәлил балалар музыка мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе;

Татарстан Республикасы Спас муниципаль районының «Болгар балалар сәнгать мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль автоном оешмасы;

Татарстан Республикасы Тәтеш муниципаль районының «Тәтеш балалар сәнгать мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе;

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районының «Балалар сәнгать мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе;

Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының «Чирмешән балалар сәнгать мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе;

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Урыссу балалар сәнгать мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе;

Казан шәһәренең «2 нче балалар музыка мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе;

Казан шәһәренең «Рөстәм Яхин исемендәге 3 нче балалар музыка мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе;

Казан шәһәренең «4 нче балалар музыка мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе;

Казан шәһәренең «5 нче балалар музыка мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе;

Казан шәһәренең «Ә.З.Бакиров исемендәге 6 нчы балалар музыка мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе;

Казан шәһәренең «А.С.Ключарев исемендәге 7 нче балалар музыка мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе;

Казан шәһәренең «8 нче балалар музыка мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе;

Казан шәһәренең «9 нчы балалар сәнгать мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе;

Казан шәһәренең «10 нчы балалар музыка мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе;

Казан шәһәренең «11 нче балалар музыка мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе;

Казан шәһәренең «Балалар музыка-хор мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе;

Казан шәһәренең «13 нче балалар музыка мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе;

Казан шәһәренең «14 нче балалар музыка мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе;

Казан шәһәренең «15 нче балалар музыка мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе;

Казан шәһәренең «О.Л.Лундстрем исемендәге 16 нчы балалар музыка мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе;

Казан шәһәренең «С.З.Сәйдәшев исемендәге 17 нче балалар музыка мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе;

Казан шәһәренең «М.М.Мозафаров исемендәге 18 нче балалар музыка мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе;

«Васильево балалар сәнгать мәктәбе» өстәмә белем бирү муниципаль бюджет учреждениесе;

«Муса Җәлил исемендәге Татар академия дәүләт опера һәм балет театры» дәүләт бюджет учреждениесе;

«Габдулла Тукай исемендәге Татар дәүләт филармониясе» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе;

«Салих Сәйдәшев исемендәге Зур концерт залы» Татарстан Республикасы дәүләт бюджет мәдәният учреждениесе;

«Татарстан Республикасының Дәүләт академия симфоник оркестры» Татарстан Республикасы дәүләт автоном мәдәният учреждениесе;

«Ля Примавера Казан камера оркестры» Казан шәһәре муниципаль автоном мәдәният учреждениесе;

«Зеленодольск музыка театры» муниципаль бюджет учреждениесе;

«София Губәйдуллинаның заманча музыка үзәге» Казан шәһәре муниципаль бюджет мәдәният учреждениесе;

«Орган залы» Яр Чаллы шәһәре муниципаль автоном мәдәният учреждениесе;

«Сара Садыйкова исемендәге Концертлар залы» Яр Чаллы шәһәре муниципаль автоном мәдәният учреждениесе;

«Түбән Кама шәһәренең концертлар-иҗат үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе;

«Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районының «Әлмәт» милли-мәдәни үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе.

---